**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

« 02 » 07 2021 ел №1746

Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын актуальләштерү максатында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә, Башкарма комитетның «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 елның 6 августындагы 3794 номерлы карарына таянып,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

1.1. Җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын.

1.2. Җирләрне яки җир кишәрлекләрен билгеле бер категориягә кертү яисә җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын.

1.3. Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын.

1.4. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне, аларның арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырганда, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын.

1.5. Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын.

1.6. Территориядә җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын.

2. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 8 февралендәге 320 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1.18, 1.23., 1.24., 1.25 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны ТР Тукай муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе вазыйфаларын башкаручыга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хабибуллин